**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"20" ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күңгәр торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күңгәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

а) Күңгәр авылында су чыгару башнясын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары һәм насос сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күңгәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Гарипова Г.Х.